КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 сентябрь

г.Казань

№ 676

2025/2026 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында

2025/2026 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2025 елның 15 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын 2025/2026 елның кышкы чорына әзерләү чаралары комплексын эшләүне оештырырга;

2025 елның 3 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка мәнфәгатьле башкарма органнары белән берлектә «Буран» оператив планына төзәтмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы медицин учреждениеләренең кар көртләре, автомобиль һәлакәтләре нәтиҗәсендә тоткарланып калган затларга үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү буенча гамәлләргә әзерлеген тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2025 елның 1 октябренә кадәр киләсе чорга җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзүне;

юл-коммуналь хезмәтләрне кышкы шартларда эшләүгә әзерләүне оештыруны һәм аларга шәһәрләрнең һәм районнарның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә кирәкле урам-юл челтәрен һәм җирле автомобиль юлларын карап тоту өчен кар чистарту техникасын беркетүне гамәлгә ашыруны;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив планнарга төзәтмәләр кертүне;

сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, 2025/2026 елның кышкы чорында куркыныч метеорологик хәлләр килеп чыкканда гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында калган затларны кайнар аш һәм азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнә торган оешмаларны билгеләүне.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсенә – 2025/2026 елның кышкы чорында табигый гидрометеорология күренешләре һәм атмосфера процесслары үзгәрү фаразы турында Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына үз вакытында мәгълүмат кертүне;

республика территориясендә «Буран» планын гамәлгә керткәндә законнар нигезендә Казан гарнизоны башлыгына – Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында кар көртләрен бетерү һәм кар көртләренә эләккән кешеләрнең тормышын коткару өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының шәхси составын, хәрби уку йортларына һәм хәрби частьләренә караган махсус һәм автомобиль техникасын бирүне күздә тотуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә – Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тотуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы бүлекчәләренә кар көртләре өелгән урыннарга юл техникасы һәм махсус техника керүне, шулай ук кешеләрнең, шул исәптән балаларның зур төркемнәрен алып бара торган автомобиль колонналарын һәм махсуслаштырылган күчмә җәмәгать туклануы һәм сәүдә формированиеләрен, зыян күргәннәргә медицина ярдәме күрсәтүче төркемнәрне транспорт вакытлыча тупланган урыннарга үткәрүне оештыруда ярдәм күрсәтүне;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлына һәм «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Куйбышев тимер юлына – Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән Татарстан Республикасы территориясеннән уза торган тимер юлларда кар көртләрен бетерүгә эшчеләр һәм техника бирү турында шартнамәләр төзүне.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024/2025 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2024 ел, 2 сентябрь, 717 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин